**СОВЕТ ГОРОДА МАМАДЫШ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. М. Джалиля, 23/33, г. Мамадыш, 422190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МАМАДЫШ ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**
М.Җәлил ур., 23/33, Мамадыш ш., 422190

тел.:(85563) 3-15-90, факс 3-24-00 ; e-mail:gorsovet.mamadysh@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 1-33** **от « 1 » октября 2019 г.**

Референдум уздыру инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 маддәсе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 маддәләре, "Җирле референдум турында» 2004 ел, 23 март, 23-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 12 маддәсе, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 11 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре Советы

К А Р А Р Б И Р Д Е:

1.Түбәндәге сораулар буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм Бөек Ватан сугышында катнашканнарның тол хатыннары, тыл хезмәтчәннәре, хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, концлагерь тоткыннары, репрессияләнгәннәрдән кала, 2020 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Мамадыш шәһәре территориясендә пляжны төзекләндерү;
- «Төньяк» поселогында халыкның массакүләм ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру;
- шәһәр урамнарында тротуарлар ясау.

« ӘЙЕ » « ЮК »

3. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында, "Интернет" мәгълүмати-коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында http://mamadysh.tatarstan.ru/ веб- адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемә алам.

Шәһәр башлыгы,
Мамадыш муниципаль районы
Мамадыш шәһәре Советы рәисе А.П.Иванов